КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 октябрь г.Казань № 1071

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Электрон мәгарифе» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 23 декабрь, 1011 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Электрон мәгарифе» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 23 декабрь, 1011 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 май, 441 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Системаның дәүләт заказчысы - «Татарстан Республикасының санлы трансформациясе үзәге» дәүләт казна учреждениесе, аның вәкаләтләрен системаның эшләвенә бәйле дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт заказчысы вәкаләтләренә таянып, системаны үстерү чараларын үткәрүне методик озата бару буенча;»;

бишенче абзацта «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесен» сүзләрен «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин